ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» сентябрь 2020 ел № 271

**Әгерҗе муниципаль районында җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокукны сату буенча ачык аукцион уздыру турында**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Торак пунктларның җирләре составыннан җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокукны сату буенча аукцион үткәрергә һәм аукционга җир кишәрлекләре чыгарырга.
2. Аукцион комиссия составын расларга (1 нче кушымта).
3. Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокук сату өчен куела торган җир кишәрлекләренең исемлеген, бәяләү бәясе күләмен, сату өчен куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләмен («Аукцион адымын») расларга (2 нче кушымта).
4. Аукцион үткәрү һәм аның нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәрне «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») район газетасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм сатулар һәм җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсе төзүгә хокукны сату буенча ачык аукцион уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (https://torgi.gov.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**